АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.12.2016 г. № 48

Казан

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында эшкә урнашканда ришвәтчелек куркынычы булган, эшкә урнашучы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары, шулай ук хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында**

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Ришвәтчелеккә каршылык күрсәтү турында»гы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы «Эшкә урнашканда дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары, шулай ук хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»гы Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы « Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларына дәгъва иткән гражданнарның үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә

караган бурычлары, һәм шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары турында мәгълүмат бирүе турында»гы Указын гамәлгә кую максатыннан

БОЕРАМ:

1. Түбәндә беркетелгән Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында эшкә урнашканда ришвәтчелек куркынычы булган, эшкә урнашучы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары, шулай ук хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары Исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Юридик бүлегенә:

2.1. Исемлектәге вазыйфаларны башкарган дәүләт гражданлык хезмәткәрләре эштән азат ителгәндә, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Ришвәтчелеккә каршылык күрсәтү турында»гы Федераль законның 12 маддәсе билгеләгән чикләүләрне, бурыч һәм җаваплылык дәрәҗәсен аңлатырга.

2.2. Исемлеккә кергән вазыйфалардагы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә әлеге боерыкны җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 2016 елның 18 мартындагы 2 номерлы «Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында эшкә урнашканда ришвәтчелек куркынычы булган, эшкә урнашучы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары, шулай ук хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»гы боерыгы үз көчен югалтты дип санарга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И.Минуллина

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы боерыгы белән расланган
«20»12.2016ел.
№ 48

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында эшкә урнашканда ришвәтчелек куркынычы булган, эшкә урнашучы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары, шулай ук хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, шәхси милеге һәм шәхси милеккә караган бурычлары хакында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары Исемлеге**

| **№№ пп** | **Вазыйфа атамасы** | **Вазыйфалар саны** |
|---|---|---|
| | **Җитәкчелек** | |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 1 |
| | **Инвестицион проектларны тикшерү бүлеге** | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| 2 | Төп киңәшче | 2 |
| | **Инвестицион проектларга ярдәм күрсәтү һәм аларны алып бару бүлеге** | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| 2 | Төп киңәшче | 2 |
| 3 | Төп консультант | 1 |
| | **Мәгълүмати-аналитик бүлек** | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| | **Дәүләт һәм шәхси эшмәкәрлек партнерлыгын үстерү бүлеге** | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| | **Юридик бүлек** | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| | **Исәп-хисап һәм дәүләт хисабына сатып алу бүлеге** | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| 2 | Төп белгеч | 1 |
| | **Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш секторы** | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| | **Материаль-техник яктан тәэмин итү секторы** | |
| 1 | Сектор мөдире | 1 |
| | Барлыгы: | 16 |